| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.12.2019 № 1869

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2019-2023 елларга Алабуга муниципаль районында һәм урта эшкуарлыкны үстерү» 2019 елның 13 маендагы 738 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» 209-ФЗ номерлы Федераль закон, 2010 елның 21 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 октябрендәге «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» ярдәмче программасы һәм Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2019-2023 елларга Алабуга муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» 2019 елның 13 маендагы 738 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2019-2024 елларга Алабуга муниципаль районы кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү».

2. «2019-2024 елларга Алабуга муниципаль районы кече һәм урта эшкуарлык субъектларын үстерү» муниципаль программасын расларга.

3. Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйковага) җирле бюджет хисабына «2019-2024 елларга Алабуга муниципаль районы кече һәм урта

эшкуарлык субъектларын үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны күздә тотуны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.Ф. Нургаяновка йөкләргә.

Җитәкче Р.М. Нуриев